Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

11.11 2022 ел № 1

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пункты террито-риясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакы-тлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен фай-далануга ризамы":

1. Кадрәк авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);
2. Кадрәк авылының Ленин, Сосновая, Кыр,Заречная, Яшьләр эш урамнарына вак таш алу һәм ремонтлау.
3. Кадрәк авылында янгын куркынычсызлыгын беренчел чаралар белән тәэмин итү (штаттан тыш янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
4. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар һәм запас частьләр сатып алу
5. Авыл зиратына керү капкасын сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 328 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 171 кеше, бу – 52,1% тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 171 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар

җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» Кадрәкторак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Кадрәк авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

2. Кадрәк авылының Ленин, Сосновая, Кыр,Заречная, Яшьләр эш урамнарына вак таш алу һәм ремонтлау.

3. Кадрәк авылында янгын куркынычсызлыгын беренчел чаралар белән тәэмин итү (штаттан тыш янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

4. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар һәм запас частьләр сатып алу

5. Авыл зиратына керү капкасын сатып алу һәм урнаштыру.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов